КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 декабрь г.Казань № 1321

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2009 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, 952 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1332 нче, 2022 ел, 21 сентябрь, 1022 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «41 777» саннарын «44 326» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «1,51» саннарын «1,791» саннарына алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «1,51» саннарын «1,791» саннарына алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «11 958» саннарын «12 688» саннарына алмаштырырга;

13 пунктта «ике процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктның алтынчы абзацында «ике процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин